КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 июль г.Казань № 607

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 316 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 26 гыйнвар, 20 нче; 2007 ел, 28 апрель, 149 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 38 нче; 2008 ел, 25 июль, 534 нче; 2009 ел, 5 март, 125 нче; 2009 ел, 8 май, 283 нче; 2010 ел, 10 декабрь 1033 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 533 нче; 2012 ел, 10 март, 205 нче; 2012 ел, 9 июнь, 503 нче; 2013 ел, 18 март, 175 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 946 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 254 нче; 2014 ел, 1 ноябрь, 842 нче; 2015 ел, 2 октябрь, 736 нчы; 2016 ел, 23 март, 157 нче; 2016 ел, 28 июль, 523 нче; 2016 ел, 17 август, 568 нче; 2016 ел, 7 декабрь, 904 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 971 нче; 2017 ел, 27 март, 188 нче; 2017 ел, 29 август, 611 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 711 нче; 2018 ел, 25 май, 398 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1215 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 25 июль, 619 нчы; 2019 ел, 13 ноябрь, 1038 нче; 2020 ел, 3 февраль, 68 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта татар текстында «азык-төлек иминлеген тәэмин итү өлкәсендә» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасында органик продукция җитештерү өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта:

тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек өлкәсендә иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү (01.23).»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07);

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән урман фондын файдалану, саклау, яклау һәм урманнарны яңадан торгызу, урман үрчетү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.06.04);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

энергия һәм ресурсларны саклау белән идарә итү (01.14);

сәнәгать белән идарә итү (03.01);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән территориаль планлаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.05.01);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән транспорт һәм юл комплекслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән цифрлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

озак вакытлы этапка исәпләнгән социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.01);

планлаштырыла торган елга социаль-икътисадый программалаштыру (01.01.02*);

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09);

инновацион эшчәнлекне үстерү белән идарә итү (01.11);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17);

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты белән балыкчылык, су объектларын һәм биологик су ресурсларын файдалану һәм саклау функциясен гамәлгә ашырганда (01.06.05);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04);

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән туризм өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.09);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләти-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр, инвестиция проектларын тормышка ашыруны комплекслы алып бару өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.10);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.10).»;

3.3 пунктта:

унөченче абзацта «продукция (товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр) белән тәэмин итүгә заказлар урнаштыруның» сүзләрен «товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыручы» сүзләренә алмаштырырга;

утыз алтынчы абзацта «заказлар урнаштыру» сүзләрен «товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыруга» сүзләренә алмаштырырга, «заказ урнаштырудан» сүзләрен «товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашырудан» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«органик продукция җитештерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшли;

Татарстан Республикасы территориясендә органик продукция җитештерүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме күрсәтүне тормышка ашыра;

органик продукция җитештерү өлкәсендә мәгълүмати һәм методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин